# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) беренче абзацта "Әлеге Кодекс" сүзләрен "1. Әлеге Кодекс" сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:
"2. Әлеге Кодекста кулланыла торган бүтән төшенчәләр федераль законнардагы мәгънәсендә кулланыла.";

2) 8 статьяның 1 өлешендә:
а) егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"урман фонды җирләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне), яклауны (урман патологиясе мониторингыннан гайре), торгызуны (урман орлыкчылыгыннан гайре) оештыру һәм шушы җирләрдә урманнарны саклауны, яклауны, торгызуны (шул исәптән урманнарны саклау, яклау һәм торгызу өчен билгеләнгән урман юлларын булдыруны һәм эксплуатацияләүне) тәэмин итү;";
б) егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген һәм урманнарда дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү;";

в) түбәндәге эчтәлекле яңа егерме бишенче һәм егерме алтынчы абзацлар өстәргә:

"региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне оештыру;

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны оештыру;";

г) егерме бишенче абзацны егерме җиденче абзац дип санарга;

3) 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

"5. Әлеге статья нигезләмәләре дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген башкарганда кулланылмый.";

4) 135 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Аучылык ресурслары исемлеге федераль закон һәм әлеге Кодекс белән билгеләнә.";

б) түбәндәге эчтәлекле 3 һәм 4 өлешләр өстәргә:

"3. Федераль закон белән билгеләнгәннәрдән тыш, аучылык ресурсларына ала карга керә.

4. Татарстан Республикасы аучылык җирләре территорияләрендә промысел аучылыгы гамәлгә ашырыла торган аучылык ресурсларына елга кондызы, ондатра, урман сусары керә.";

5) түбәндәге эчтәлекле $135^1 – 135^7$ статьялар өстәргә:

"$135^1$ статья. **Аучылык җирләре**

1. Аучылык җирләре чикләренә хокукый режимы аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру рөхсәт итә торган җирләр кертелә.

2. Аучылык җирләре түбәндәгеләргә бүленә:

1) федераль закон белән каралган нигезләрдә юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кулланыла торган аучылык җирләренә;

2) аучылык максатларында физик затлар ирекле кереп йөрү хокукына ия булган аучылык җирләренә (алга таба – һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре).

3. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре Татарстан Республикасы аучылык җирләренең гомуми мәйданыннан кимендә егерме процентын тәшкил итәргә тиеш.

4. Аучылык җирләре аучылыкның бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру өчен кулланылырга мөмкин.

135$^{2}$ статья. **Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау**

1. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау түбәндәгеләрне даими рәвештә күзәтүләр системасыннан гыйбарәт:

1) аучылык ресурсларының санын һәм таралышын, аларның яшәү тирәлегендә урнашуын, аучылык ресурсларының торышын һәм аларның төрләре буенча үзгәреше динамикасын;

2) аучылык ресурслары яшәү тирәлегенең һәм аучылык җирләренең торышын.

2. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау әйләнә-тирә мохитне дәүләт тарафыннан мониторинглау өлеше булып тора.

3. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау күрсәткечләрен аучылык ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны, аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклауны оештыру өчен кулланыла.

4. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау күрсәткечләрен вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына тапшыра.

6. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау һәм аның күрсәткечләрен куллану тәртибе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

135$^{3}$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрын алып бару**

1. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрын алып бару аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге дәүләт аучылык хуҗалыгы реестры күрсәткечләрен вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына тапшыручы вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрын алып бару, андагы документлаштырылган мәгълүматны җыю һәм саклау, шулай ук мондый мәгълүматны алып бару һәм кызыксынучы затларга бирү вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Әлеге мәгълүматны алмашу вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән рәвешләр буенча гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрын алып бару аны алып бару технологиясенең бердәмлеге, андагы документлаштырылган мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуын һәм аны

актуальләштерүнең өзексезлеген тәэмин итү, мондый мәгълүматны башка дәүләт мәгълүмат ресурсларындагы документлаштырылган мәгълүмат белән чагыштырып булу принциплары нигезендә кәгазь һәм электрон чыганакларда гамәлгә ашырыла.

135[4] статья. **Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә нормалаштыру**

1. Аучылык ресурсларын киңәйтелгән торгызу өчен кирәкле чикләрдә аларның санын саклап калырлык хәлдә тоту аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативларны һәм нормаларны эшләү, билгеләү һәм үтәү юлы белән тәэмин ителә.

2. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативларга аучылык ресурсларын аерып алу мөмкинлеге нормативлары, шулай ук аучылык җирләрендәге аучылык ресурслары саны нормативлары һәм биотехник гамәлләр нормативлары керә.

3. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормаларга аучылык ресурсларын аулау мөмкинлеге нормалары һәм аучылык җирләренең аучылар йөрү мөмкинлеге нормалары керә.

4. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативлар вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан эшләнә һәм раслана.

5. Үзләренә карата аулау лимиты билгеләнмәгән аучылык ресурсларын аулау мөмкинлеге нормалары һәм аучылык җирләренең аучылар йөрү мөмкинлеге нормалары аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

135[5] статья. **Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында бүлү тәртибе**

1. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр аучылар арасында бүленә.

2. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын алу өчен аучылар аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына гариза белән мөрәҗәгать итәләр, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның адресы һәм контакт телефоны, аучылык билеты турындагы белешмәләр;

2) территориясендә аучы аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга хокук алырга ниятләгән аучылык гамәлгә ашырыла торган һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре урнашкан муниципаль берәмлек исеме;

3) аучылык ресурсы төре.

3. Аучы муниципаль берәмлекләрнең берәрсенең һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре территорияләрендә аучылык ресурсларының һәр төрен аулауга рөхсәт алу хокукын алу өчен бер гариза бирергә хокуклы.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гаризаларны аучылар аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтле башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән срокларда бирә.

5. Тояклы хайваннар аулауга рөхсәт алу хокукы, аларны аулау квотасыннан чыгып, гаризалар биргән аучылар арасында очраклы сайлап алу (шобага) юлы белән бүленә.

6. Шобаганы аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан төзелә торган комиссия үткәрә. Комиссия составына җәмәгатьчелек вәкилләре кертелә.

7. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында, шулай ук Интернет челтәрендәге үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне урнаштыра:

1) гаризалар бирү сроклары турында;

2) шобага үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында;

3) шобага йомгаклары турында;

4) шобага үткәрүче комиссия составы турында.

8. Комиссия территорияләрендә һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре урнашкан муниципаль берәмлекләр буенча һәм аучылык ресурслары төрләре буенча аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукына дәгъвалаучылар исемлеген шобага үткәрү өчен номерлар булган гаризаларның теркәү номерлары нигезендә төзи. Шобага аучылык ресурсларының һәр төре буенча үткәрелә.

9. Шобага, лототрон кулланып, номерларны очраклы сайлап алу алымы белән үткәрелә, бу лототронга номерлы конвертлар (контейнерлар) урнаштырыла. Лототронны әзерләү һәм һәр конвертны (контейнерны) карап чыгу комиссия тарафыннан башкарыла. Шобага гавами рәвештә үткәрелә, аны үткәргәндә аучылар, аларның вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин.

10. Шобага үткәрү нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, аңа комиссия әгъзалары имза сала. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) территорияләрендә һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре урнашкан муниципаль берәмлекләрнең берәрсенең һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә игълан ителгән аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукына ия булган аучылар;

2) территорияләрендә һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре урнашкан муниципаль берәмлекләрнең берәрсенең һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә игълан ителгән аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын алырга мөмкин булган аучылар, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын әлеге өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән аучылар гамәлгә ашырмаган очракта яисә аучылык ресурсларын аулау квоталары арттырылган очракта;

3) тояклы хайваннарны аулау квоталары булмаганга күрә, муниципаль берәмлекләрнең үзләренә карата шобага үткәрелмәгән һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләре.

11. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы шобага үткәрелгәннән соң ун

көн эчендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукына ия булган аучыларга шобага нәтиҗәләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

12. Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәткә алынган хокук хәбәр алынган мизгелдән утыз көн эчендә аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына мөрәҗәгать итү юлы белән аучы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

13. Аучы аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын гамәлгә ашырмаган очракта, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы әлеге статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга шобага үткәргәндә билгеләнгән чират тәртибендә аларның аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы барлыкка килү турында язма рәвештә хәбәр итә.

14. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә тояклы хайваннарны аулау квоталары ау сезоны эчендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә арттырылган очракта, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр алу хокукы әлеге статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга шобага үткәргәндә билгеләнгән чират тәртибендә бирелә, бу хакта аларга аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан язма рәвештә хәбәр ителә.

15. Әлеге статьяның 13 һәм 14 өлешләрендә каралган очракларда аучылар тарафыннан аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

16. Аучыларның гаризалары саны муниципаль берәмлек территориясендәге һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә тояклы хайваннарны аулау квотасыннан артмаган очракта, шобага үткәрелми һәм аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр гаризалар биргән аучылар арасында бүленә.

17. Аучылык ресурсларын, тояклы хайваннардан тыш, аулауга рөхсәтләр аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына мөрәҗәгать иткән аучылар арасында аучылык җирләрендә аучылар йөрү мөмкинлеге нормаларын, аучылык ресурсларын аулау мөмкинлеге нормаларын, аучылык ресурсларын аерып алу мөмкинлеге нормативларын исәпкә алып бүленә. Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукын бирү чираты мөрәҗәгатьләр керү чиратына туры килергә тиеш.

18. Һәркем өчен мөмкин булган аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр бирү аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

135$^{6}$ статья. **Дәүләт аучылык контроле һәм күзәтчелеге**

Дәүләт аучылык контроле һәм күзәтчелеге, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә законнар нигезендә билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү максатларында, дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

135[7] статья. **Җитештерү аучылык контроле**

Җитештерү аучылык контроле аучылык хуҗалыгы килешүләре төзегән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

6) 165 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:
"8. Калдыкларны урнаштыру объектларының дәүләт реестрына кертелмәгән объектларда калдыклар урнаштыру тыела.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 30 июне
№ 39-ТРЗ